**Мөхетдинова Алсу Назым кызы, Хәсәнова Фәһимә Габдулла кызы.**
**МБГБУ "Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Чәчкаб төп гомумбелем бирү мәктәбе"нең башлангыч сыйныф укытучылары.**

**Кичәнең темасы : Татарстан минем Ватаным.**

**Максат:** Ватаныбыз Татарстан турында алган белемнәрне ныгыту һәм тирәнәйтү. Балаларда туган якның тарихын . мәдәниятен, табигатен өйрәнүгә кызыксыну уяту. Мәдәни мираска сакчыл караш тәрбияләү.

**Аңлатма язу**

Быелгы уку елында “Татарстан мирасы” дигән курс буенча дәрестән тыш эшчәнлек алып бара башладык.

Монда Татарстанда яшәүче халыкларның мәдәни, тарихи, сәнгати дөньясына сәяхәт формасында алып барабыз. Шулай ук халыкларның бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре,борынгы риваятьләр,мәшһүр шәхесләр белән таныштык. Безгә ярдәмгә Зөләйха, Роман һәм Ак Бүре килделәр. Балаларга кызыклырак булсын өчен кайбер көнне укытучылар үзебез Ак Бүре яки Шүрәле баласы булып киенеп төрле мәгълүмат бирдек, уеннар уйнаттык. Чирек ахырында йомгаклау кебек бәйрәмнәр, викториналар уздырдык.. Материалны “Татарстан мирасы.” татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / [төзүчеләре: М. М. Гибатдинов, Л. Р. Мортазина] китабыннан, интернеттан алдык.Һәрбер чарага презентация әзерләргә тырыштык, шулай ук балаларга өйгә төрле иҗади эшләр бирдек (Сораштыру,рәсем ясау, шигырь, хикәя иҗат итү). Әти-әниләрне дә бу эшкә җәлеп итәргә тырыштык. Балаларда Туган илне ярату, аны саклау хисен булдырырга тырыштык.

Бер чараны тәкъдим итәргә булдык.

**Кичә барышы:**

**I Кереш өлеш.**

Укытучы: Нинди матур минем Туган илем,

Җир шарында тиңнәр юк аңар!

Киң кырларда үсә мул игеннәр,

Шаулап ага озын елгалар.

- Без бүген нәрсә турында сөйләшербез икән? (Туган ил турында).

**II Төп өлеш.**

1. **Татарстанда яшәүче халыкларның милли киемнәре.**

- Безнең туган илебезнең исеме ничек? (Россия)
- Россия бик зур ил , аның территориясе өлкәләргә, крайларга, республикларга бүленгән. Без нинди республикада яшибез? (Татарстан)

Россия картасы һәм анда Татарстан күрсәтелгән.

-Россиянең кечкенә генә бер өлеше булса да ,Татарстан Россия тормышында зур урын алып тора. Татарстан булгач, анда татарлар гына яшидер инде, әйеме? (Юк, Татарстанда төрле милләт яши. Балалар әйтеп чыгалар.)

- Милләтләр бер-берсеннән нәрсә белән аерыла соң? (тел, гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәре, милли киемнәре белән аерыла).

-Игътибар белән экранга карагыз әле, нинди халыкларның милли киемнәрен күрәсез, нинди элементларына карап ачыкладыгыз ? (Бизәкләргә, хатын-кызларның баш киеменә карап)

-Татар хатын – кызларның баш кииеме ничек атала? (калфак).

**2. Татар халкының милли киемнәре.**

-Татар халкы элек- электән бик матур киенергә яраткан. Чигелгән түбәтәйләре,берсеннән-берсе матур калфаклары, бизәкле читекләре белән дан тоткан. Карагыз әле, калфаклар нинди төрле булганнар. Ни өчен икән, кайсыгыз белә? (Балалар фикере).

-Моннан 150 еллар элек чуклары аркага төшеп торган, чәчне тулысынча каплаган калфаклар – капчык калфаклар – кигәннәр. Яңа кием стиле барлыкка килгәч (19 гасырның икенче яртысыннан) калфаклар кечкенәйгәннәр: каты

кырпулы калфаклар, такыя калфаклар (кәләпүш формасында) өстенлек ала. Татар халкының яраткан композиторы Сара Садыйкова да калфак кияргә бик яраткан. Аны халык яратып “калфаклы сандугач” дип йөрткән. Татар халкының аяк киемнәре дә күп төрле. Ирләр читекләре йомшак кара күннән тегелгән. Яшь хатыннар һәм кызлар биек үкчәле каюлы читекләр кияргә яратканнар.

-Фотосурәткә игътибар итегез әле. Сез кемне таныйсыз? (С.Есенин). Ул кем булган? Аның янәшәсендәге хатын-кыз кем дип уйлыйсыз? (Балалар фикере). Бу Есенинның хатыны Айседора Дункан. Ул Американың атаклы биючесе булган. Аякларына карагыз әле, ул нәрсә кигән? (Читек). Ник кигән икән? (Матур булганга).

-Дункан татар милләтеннән булмаса да татар читекләрен бик яратып кигән, чөнки читекләр матур гына түгел, ә аякка уңайлы, җиңел булганнар.Димәк, читекләрне безнең халкыбыз матур булганга гына түгел, ә җиңел, уңайлы булганга да кигән.

**3. Казанга сәяхәт.**

Укытучы: И, Казан, нурлы Казан, моңлы Казан...

- Безнең башкалабыз Казан шәһәре. Без сезнең белән анда барганыбыз да бар. Гаиләләрегез белән дә барганыгыз бар.Аның нинди тарихи . истәлекле урыннары белән таныштык? (Кремль, Сөембикә манарасы, Мәрҗәни мәчете, Университет һ.б.) слайдта күрсәтелә. Бүген дә Казанга сәяхәткә барырбыз. Карагыз әле бу урынны, кайсыгыз белә?(Балалар фикере)

-Татарстанның милли музее бу. Музейда үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшереп китик әле. (Балалар әйтә).

-Сезнең анда булганыгыз бармы? Нәрсәләр карадыгыз? (балалар фикере)

-Татарстанның милли музее ике катлы бинада урнашкан. 1895 нче елда ачыла. Ул тарихчы,коллекционер, төбәкне өйрәнүче Андрей Федор улы Лихачев коллекциясеннән башлана. Хәзерге вакытта анда 800 000 экспонат бар.Алар туган якның тарихын, табигатен, Идел буе, Урал алды, Руссия һәм дөнья халыкларының тормышын өйрәнү өчен файдаланыла. Музейда бүлекләр күп:

Лихачевның болгар тупланмасы, алтын тәңкәләр, 15-20 гасыр кулъязма китаплар, Державино мемориаль комплексы һәм башкалар. Бер экспонат безнең Кайбыч районыбыз белән бәйле.
Аның турында нәрсәләр беләсез? (Петр патша корабльләр төзергә имән агачларын безнең яктан ташыткан).

**4. Ял итү.** "Шүрәле" җыры яңгырый һәм Шүрәле булып киенгән укытучы керә. Балаларны кетекли башлый.
-Кем икән бу? Безнең бүгенге чарабызга аның нинди кагылышы бар? (Шүрәле малае безне республикабыз халыкларының төрле уеннары белән таныштыручы).
-Нинди уеннар уйнарга өйрәндегез? (Балалар атыйлар). Уенны сайлыйлар.
Шүрәле бер уенны уйната .балаларны ял иттерә.

**5. Атаклы шәхесләребез.**
-"Шүрәле" әкиятен кем язган? Безнең Татарстанны, татар халкын бөтен илгә таныткан шәхесләребезнең берсе ул. Ә тагын нинди данлыклы, атаклы шәхесләребез турында сөйләштек? (балалар фикере).
-Менә сез Шишкин фамилиясен атадыгыз . Кем булган ул?Ни өчен без аны данлыклы шәхесебез дибез? (балалар фикере)
-Әйе. Ул бөек рәссам. Алабуга шәһәрендә Шишкин музей-йортында 52 әсәрнең төп нөсхәсе саклана. Аның әти-әнисе улларының рәсем ясау белән мавыгуын өнәмиләр, бигрәк тә әнисе. Һәм Шишкин алардан качып, рәсемнәрен төнлә шәм яктысында ясый. Бераздан әтисе улының рәсемнәрен күрә һәм сәләтле икәнен аңлап Мәскәүгә укырга җибәрә. Шишкин үзенең таланты, тырышлыгы, эшсөючәнлеге аркасында танылган рәссам була. Күп кенә рәссамнар картиналарында иртәнге яки кичке вакытны сурәтләүне хуп күрәләр. Ләкин Шишкин исә көндезге вакытны, төш вакытын сурәтләргә яраткан.Русчалатып әйткәндә, Шишкин – художник полудня. Россиядә 5 рәссам гына шул вакытны төгәл ясаган һәм шуларның берсе безнең якташыбыз. Аның данлыклы картинасы "Нарат урманында бер иртә" (1889) турында нәрсәләр беләсез? (Балалар фикере).

-Бу картинаны дусты Константин Савицкий дигән рәссам белән берлектә туган. Аюларны ул ясаган. Шишкин үзе дә аларны ясаган булган , эскизлары саклanган. Ләкин ул Савицкий ясаган аюларны матуррак дип санаган. Третьяков галереясында Третьяков , мин бер рәссамныкы гына булсын дигән идем дип, Савицкий фамилиясен картинада бетерттерә. Рәссам башта каршы килсә дә аннары ризалаша, Шишкинның өлеше күбрәк ди ул. Кайберләре бу рәсемдә 3 аю баласы һәм тагын ана аю дип тә әйтәләр. Чыннан да, агач төбендәге аю зуррак та. Сез бу рәсемне тагын кайда күргәнегез бар? (Коверда, конфет коробкасында, конфет пичәтендә...).

**III. Йомгаклау өлеше.**

-Атаклы якташыбыз нинди сыйфатларга ия булган? (максатчан, тырыш, сәләтле, үҗәт.)

Димәк, сезнең дә һәрберегезнең ниндидер сәләте, хыялы бардыр. Аңа ирешер өчен бик тырышырга, максатчан булырга кирәк. Менә шундый тырыш, максатчан, эшчән кешеләребез булганда безнең Татарстаныбыз тагын да үсәр, матураер, тагын да танылыр.